СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 1-16 от «31» октября 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына генераль планны әзерләүнең кирәк булмавы турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары, «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон, Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 июлендәге 10-53/9067 нче номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турындагы проектына карата бәяләмәсе (кушымталарга туры китереп) нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2020елның 26 октябрендәге 3-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына түбәндәге торак пунктлары чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертергә:

- Югары Ушма авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Югары Ушма, Алкин, Акчишмә, Иске Завод, Хәсәнша авыллары;
- Дүсмәт авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Комазан башы авылы;
- Көмешкүл авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Алгай авылы;
- Келәүш авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Тугыз, Пойкино, Сарбаш, Чупай авыллары;
- Көек-Ерыкса авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Яңа Комазан, Гришкино, Каргалы, Яңа Чиркәс, Иске Чиркәс авыллары;
- Кече Кирмән авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Югары Яке, Норма, Су-Елга;
- Түбән Сон авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Түбән Сон, Колышчы авыллары;
- Олыяз авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Олыяз, Югары Козгынчы, Дусай, Тулбай авыллары;

000090

- Урта Кирмән авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Урта Кирмән, Арташ авылы;

- Сон авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Югары Сон авылы;

- Усали авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Бөрсет- Сукачы, Югары Бөрсет, Владимир, Күкчишмә авыллары;

-Шәдче авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Шәдче, Вахит, Иске Мочалкино, Юкәче авыллары;

- Шәмәк авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Шәмәк, Иске Чәбия авыллары;

- Яке авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Дегетле, Покровка авыллары.

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (http://madysh.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча муниципаль район Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П. Иванов